**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«НОВОТРОИЦК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

«25» сентябрь 2023 ел № 35/1

**2023 елның ярты еллыгы өчен Новотроицк авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап**

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе Габделхаева Дамира Махаматнуровна «2023 елның ярты еллыгы өчен Новотроицк авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап» хакында мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2023 елның ярты еллыгы өчен Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисапны керемнәр буенча 6 168,67 мең сум, чыгымнар буенча 6 173,27 мең сум күләмендә түбәндәге күрсәткечләр белән расларга:

- 2023 елның ярты еллыгы өчен Новотроицк авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары буенча әлеге карарга 1 кушымта нигезендә.
- 2023 елның ярты еллыгы өчен Новотроицк авыл җирлеге бюджеты керемнәре буенча әлеге карарга 2 кушымта нигезендә.
- 2023 елның ярты еллыгы өчен Новотроицк авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы буенча әлеге карарга 3 кушымта нигезендә.
- 2023 елның ярты еллыгы өчен Новотроицк авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бүлекләр һәм бүлекчәләр, максатчан статьялар һәм чыгымнар төрләре буенча бүлүнең функциональ структурасы буенча әлеге карарга 4 кушымта нигезендә.
- 2023 елның ярты еллыгы өчен Новотроицк авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен максатчан статьялар (муниципаль программалар һәм эшчәнлекнең программадан тыш юнәлешләре) чыгымнар төрләре төркемнәре, бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бүлүне әлеге карарга 5 кушымта нигезендә.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларда урнаштырып халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгәннән соң законлы көченә керә.

Новотроицк авыл җирлеге Башлыгы,
Совет Рәисе Д.М. Габделхаева